**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлегенең Игәнә- Баш пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Илексаз авыл җирлеге Игәнә- Баш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә- Баш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә- Баш торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә- Баш авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә- Баш пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 15 ноябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Урамнарның яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Игәнә-Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар һәм материаллар сатып алу; агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту));

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Игәнә-Баш торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Игәнә-Баш торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу)

2. Әлеге карарны Илексаз авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Ф.М.Гыйлфанов